| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.03.2016 Казан ш. № 7-4/т

Казан шәһәрендә җәмәгать транспортында даими пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән пассажирлар һәм багажны даими алып баруларны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү» турындагы 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ санлы, «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ санлы Россия Федерациясе законнарына, «Бәяләрне (тарифлар) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына нигезләнеп, «Росия Федерациясендә автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр пассажир транспорты белән пассажирлар һәм багажны даими алып баруларны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү» Федераль законын тормышка ашыру» турындагы 2015 елның 26 декабрендәге 107-ЗРТ санлы Татарстаны Республикасы законы белән, 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәре җәмәгать транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләргә, шул исәптән:

1.1. түбәндәге карарның 1 кушымтасына нигезендә автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр пассажир транспорты белән даими алып бару муниципаль маршрутлары буенча алып барулар;

1.2. түбәндәге карарның 2 кушымтасына нигезендә метрополитен белән алып барулар.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

«Казан шәһәрендә җәмәгать транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында» 2014 елның

31 гыйнварындагы 7-1/т санлы Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карарының 1нче пунктын;

«Казан шәһәрендә җәмәгать транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында»гы 2014 елның 31 гыйнварындагы 7-1/т санлы Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» гы 2014 елның 12 сентябрендәге 7-18/т карарын.

3. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
25.03.2016 № 7-4/т
карарына 1 кушымта

Казан шәһәрендә автомобиль транспорты һәм
шәһәр җир өсте электр транспорты белән даими алып бару
муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар һәм багаж алып баруга
максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| Транспорт төре | Бер тапкыр транспортта бару һәм 1 урын багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлары (сум) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | транспорт салонында билет алган чакта (метрополитен кассасында жетон алган чакта) | озак вакыт куллану билеты белән бару өчен түләү | | |
| | | 1 бару [1] | 10 тапкыр бару [2] | 50 тапкыр бару [2] |
| Автобус | 25 | 23 | 23 | 15 |
| Троллейбус | 25 | 23 | 23 | 15 |
| Трамвай | 25 | 23 | 23 | 15 |

<1> билгеле бер бәягә барырга мөмкинлек биргән, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм;

<2> билгеле бер бәягә ничә тапкыр барырга мөмкинлек биргән, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм.

Искәрмә. Багаж алып бару өчен аерым транспортта бару бәясенә өстәп түләнелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
25.03.2016 № 7-4/т
карарына 2 кушымта

Казан шәһәрендә метрополиҗенда пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны

| Транспорт төре | Бер тапкыр транспортта бару һәм 1 урын багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлары (сум) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | транспорт салонында билет алган чакта (метрополитен кассасында жетон алган чакта) | озак вакыт куллану билеты белән бару өчен түләү | | |
| | | 1 бару [1] | 10 тапкыр бару [2] | 50 тапкыр бару [2] |
| Метрополитен | 25 | 23 | 23 | 15 |

<1> билгеле бер бәягә барырга мөмкинлек биргән, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм;

<2> билгеле бер бәягә ничә тапкыр барырга мөмкинлек биргән, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм.

Искәрмә. Багаж алып бару өчен аерым транспортта бару бәясенә өстәп түләнелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге